# Нәсыйхәт

Җомга
16
гыйнвар
2015
№29

**Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән**
**Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы**


## ♦ ЯҢАЛЫКЛАР

### МАМАДЫШ РАЙОНЫ МӨХТӘСИБЕНӘ 50 ЯШЬ

**27нче гыйнвар көнне Мамадыш районы имам–мөхтәсибе Илһам хәзрәт Миңнегалиевның 50 яшьлек юбилее уңаеннан мәҗлес булды.** Татарстан мөфтие һәм Диния нәзарәте исеменнән юбилярны мөфти урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин котлады һәм “Халыкка хезмәт өчен” күкрәк билгесе белән бүләкләде **(рәсемдә).**



Илһам хәзрәтне 50 яшьлеге белән котларга күрше район имам-мөхтәсибләре, төбәк казыйлары, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Мамадыш районы башлыгы Анатолий Иванов килде. Район башлыгы хәзрәтнең актив эшчәнлеге һәм дини кыйммәтләрне таратуга зур өлеш кертүе өчен Мактау грамотасы тапшырды.

### ЯКШӘМБЕ МӘКТӘБЕ

**Мамадыш мәдрәсәсендә олылырдан тыш балалар да укый. Якшәмбе көнне мәдрәсәдә 35ләп бала дини белем ала.** Дини уку йорты буларак, мәдрәсә балаларны ислам нигезләре белән таныштыруны, шулай ук әдәпле-әхлаклы булырга, тормыштагы



начарлыклардан читләшергә, өлкәннәргә, бигрәк тә әти-әниләргә карата хөрмәт-илтифатлылык күрсәтергә өйрәтүне максат итеп куя. Әлбәттә, укучылар төрле, белемне дә алар төрлечә үзләштерә, әмма бала нинди генә сәләткә ия булса да, аңа хәләл белән хәрамны аерырга, әти-әни, җәмгыять, ә иң мөһиме – Аллаһы Тәгалә каршында җаваплылык тоярга өйрәтергә була. Барлык балаларны безнең мәдрәсәгә чакырып калабыз!

### МӘДРӘСӘ ДИРЕКТОРЫ ҖЫЕЛЫШТА КАТНАШТЫ

**Мәдрәсә директоры Габдрахман хәзрәт урта һөнәри дини белем бирүнең уку–укыту стандартларын гамәлгә кертүгә багышланган җыелышта катнашты.** Әлеге җыелыш КФУ бинасында үтте.



Мөфти үзенең чыгышында бу стандартларның 2 ел дәвамында әзерләнүе турында әйтте. Шуңа күрә төрле дини уку йортлары мөгаллимнәреннән торган уку-укыту методик берләшмә оештырылуын билгеләде. Яңа стандартлар Татарстанның барлык мәдрәсәләренә кагыла һәм аның нигезен безнең татар дин галимнәренең мирасы тәшкил итә. Алар студентларыбызда белемнәрен үстерү теләгән арттырырга этәргеч булыр дип көтелә. “ТР МДН карамагында 8 дини уку йорты бар. Алар тиздән бердәм стандартлар буенча эшли башлаячак. Әлеге стандартлар хәзерге заман имамының идеаль үрнәген күзаллап эшләнгән. Бүгенге көндә кадрлар мәсьәләсен хәл итү, уку-укыту-программасын билгеләү, китаплар әзерләү һәм мөгаллимнәр өчен квалификация күтәрү курсларын оештыру өстендә эшләнә. Хәзерге вакытта өч юнәлештә стандартлар расланды:
“Ислам фәннәре һәм тәрбия”, башлангыч әзерлек;
“Ислам фәннәре һәм тәрбия, гарәп теле” , төп әзерлек;
“Ислам фәннәре һәм тәрбия, гарәп теле”, югары әзерлек.
Әлеге стандартлар мәгариф һәм фән министрлыгы экспертизасын уңышлы үтте. Стандартларны Татарстан мөфтие, ТР МДН рәисе Камил хәзрәт Сәмигуллин раслады (12.11.2014. №74 “Урта һөнәри дини белем бирүнең уку-укыту стандартларын раслау һәм гамәлгә кертү турындагы” боерыгы). Боерык нигезендә, 2015-2016нчы уку елыннан башлап, ТР МДНнә караган мәдрәсәләрдә шәкертләргә белем әлеге стандартлар нигезендә биреләчәк.

### УКУЛАР ОЕШТЫРЫЛА

**Мамадыш мәдрәсәсе тарафыннан район авылларында дини тәрбия бирү һәм ислам кыйммәтләрен җиткерү ниятеннән төрле әхлакый һәм тәрбияви чаралар оештырылып килә.** Мәдрәсә мөгаллимнәре авылларга җомга намазларын укытырга йөри. Кайбер авыллардан атнага өч тапкыр кешеләр үзләре мәдрәсәгә укырга киләләр. Ә менә Яңа Комазан һәм Берсут авылларына атнага бер тапкыр мәдрәсә директоры гыйлем бирергә үзе бара. Әлеге күренеш бу авылларда дин белән кызыксынучыларның күп булуы белән аңлатыла.



### УКУЧЫЛАРГА ӘДӘП–ӘХЛАК ҖИТМИ



**20нче гыйнварда Мамадыш мәдрәсәсе бинасында район имамнары һәм мөгаллимнәренең агымдагы җыелышлары булды.** Киңәйтелгән җыелышта шулай ук район башлыгы урынбасары, район мәгариф бүлеге вәкилләре һәм мәхәллә активистлары да катнашты.
Сүз мәктәпләрдә әдәп-әхлак дәресләрен үткәрү, аларны гамәлгә ашыруда үтемле ысулларны киңрәк куллану турында барды.



### ИХЛАС КҮҢЕЛ, ИЗГЕ НИЯТ БЕЛӘН

**Мәдрәсә директоры Габдрахман хәзрәт узган җомгада Әхмәт Ясәви мәчетендә намаз укыганда булырга тиешле ихласлык турында вәгазь сөйләде.**

Сәяхәт

# Аралашып яшик

**1нче февральдә якшәмбе көнне Мамадыш шәһәренең "Әхмәт Ясәви" мәчете имамы Нурислам хәзрәт Газизов җитәкчелегендәге бер төркем мөселманнар Кукмара районына экскурсиягә барып кайттылар.**



Араларында безнең мәдрәсә шәкертләре дә бар иде. Өлкәннәрдән һәм яшьләрдән торган 14 кешелек делегация иң элек Кукмара мәдрәсәсенә килеп, әлеге уку йорты эшчәнлеге белән танышты, бинаны карап чыкты, шул көнне үткәрелгән дәресләрдә катнашты. Мамадыш мөселманнары җирле "Туган якны өйрәнү музее"на да барып, анда район тарихына, узган гасырларда биредә яшәгән мөселманнар тормышына кагылышлы кызыклы фикерләр ишеттеләр.

Үзәк мәчеттә укылган өйлә намазыннан соң, мәдрәсә ашханәсендә бик күңелле аш-чәй мәҗлесе оештырылды.

Аннары Кукмара районының иң дини авылларының берсе булып саналган Аш.Бужи мәхәлләсенә юл тотты. Шунысы кызыклы – бу авыл кибетләрендә спиртлы эчемлекләр бөтенләй сатылмый икән, чөнки... алучы юк. Әйе, авыл халкының күпчелеге – намазда, Кукмара мәдрәсәсен тәмамлаучылар да шактый күп, мәчеттә 5 вакыт намаз көн саен җәмәгать белән укыла, Җомга намазында мәчет авылдашлар белән шыплап тула. Авыл кешеләренең дөнья тормышы да житешле: һәр гаиләнең үз кәсебе бар, мөселманнарның көндәлек тормышларында, эш-гамәлләрендә бәрәкәт булуы сизелә. Дәвамлы булсын, алга таба да аралашып, бер-беребезнең хәлләребезне белешеп яшәргә язсын, дип өстисе генә кала.

**ФИРАЯ МИНГАЛИЕВА**

Бу-мөһим

*Дөрес юлны табыйм дисәң,*
*Намазларга бас бүген.*
*Сихәтләнеп киткәнеңне,*
*Аңларсың шуннан үзең!*

# Күңел тынычлыгы - тән сәламәтлегенең нигезе

Безнең гыйльме (психик) һәм тән сәламәтлекләре җан тынычлыгына бәйле икәне тормышның үзе белән исбатланган. Б бәйлелек хәзерге фән (психология, тыйб, социология һ.б.) казанышлары белән дә дәлилләнгән. Ислам дине өйрәтүләре буенча бу сорауны азмы-күпме ачыкларга менә без дә алындык. Мәгълүм ки, кешенең өч асылы бар: җаны, акылы һәм бәдәне. Бәдән, ягъни безнең тән (әгъзалары белән бергә) балчыктан яратылган. Тәннең Аллаһ Раббыбыз рәхмәте белән булдырылган ихтыяҗлары: ашау, эчү, чисталык, хәрәкәт, хезмәт итү, ял, иркәләнү һ.б. Ә тәнебезгә урнаштырылган җаныбызны Бөек Аллаһ нурдан яралтты дип аңлаталар Ислам дине галимнәре. Җан мәңгелек буларак саф яки карала башлаган булырга мөмкин диләр. Безнең фараз буенча җанның сафлык дәрәҗәсе белән билгеле бер дәрәҗәдә бәйләнгән безнең гыйльме рух һәм тән сәламәтлекләре. Хәзерге тыйб (медицина) фәне өйрәтүе буенча тән сәламәтлеге төп ике факторга бәйләнгән: безнең нерв системасына һәм тән әгъзаларыбызның яшәү энергиясен тәэмин итәрдәй канга. Әйе, хәзерге вакытта кешене менә шушы әле генә әйтелгән факторлар нигезендә дәвалыйлар. Ә ислам динен кабул иткән тыйб галимнәре өйрәтүләре буенча авыруны аның асылын (җан, акыл һәм тән) белеп дәваларга кирәк. Ягъни авыруны дәвалау яхшы нәтиҗә бирә икән, әгәр аның тышкы һәм эчке сәбәпләрен белеп һәм аларны үзара тиешле тәртиптә бәйләп эш итсәләр. Мәсәлән, тыйб практикасының әйтүе буенча тәкъва мөселман (эчке сәбәп) Аллаһ әс-сәләәмү ярдәмендә дәвалау курсын (тышкы сәбәп) яхшы үткәне. Бу тыйб фәненең иммунитет бүлегенең галиме Ганс Сельенең 40 еллык тәҗрибәсе нигезендә исбатланган. Югарыда әйтелгәннәрне дәвам итеп, акылның әһәмияте турында берничә сүз. Безнең акыл җаныбызның юнәлеш бирүе нигезендә Аллаһ Тәгаләнең әманәт итеп биргән бүләген ягъни сәламәтлегебезне һәрдаим сакларга һәм ныгытырга бурычлы (фарыз). Кабат кубарылгач биреләсе 5 төрле сорауларның икенчесе: "Сәламәтлегеңне нинди урыннарга сарыф иттең?" дигәне әйтә, ягъни дәлил аның әманәт икәнен...

Ә хәзер кыскача гына булса да санап китәсебез килә бүгенге көндәге бихисап теге яки бу дәрәҗәдәге психик авыруларның сәбәпләрен һәм алардан азмы-күпме котылу юлларын.

Сәбәпләрнең берсе һәм иң әһәмиятлесе дияргә була безнең тормышның бик тә ыгы-зыгылы һәм борчулы булуы. Әйе, безнең җир шарыбызның аурасы тискәре яшәү энергиясенә баеды һәм бу әлегә дәвам итә: мәгънәсез сугышлар, төрле җирдәге һәм төрле милләттәге халыкларның еллар дәвамындагы Аллаһ Раббыбыз риза булмаган эгоистик уй-фикерләре һәм гамәлләре, җирдә яшәүче халыкларның җан тынычлыгын тәэмин итәрдәй яшәеш рәвеше булмау һәм башка илләрдән эгоистик өстенлек алырга тырышу галәмәтләре һ.б.

Теләсә кайсы илнең хәбәр бирүче чыганагына (гәҗит, журнал, радио, телевизор һ.б.) дикъкать итсәгез, ишетәсез һәм күрәсез бер генә илнең дә иң олы җитәкчесеннән алып кечкенә түрәсенә чаклы үзләренең һәм башка халыкларның гармоник яшәеш рәвеше өчен һәм шул исәптән халыкларның җан тынычлыгы өчен бернәрсә дә эшләмәгәннәрен. Әйе, аларга үзләренең эгоистик юлдагы һәм матди байлыкларын арттыру, саклау белән бәйләнгән хакимиятләрен ныгыту әһәмиятлерәк.

Җан тынычлыгына зыянлы икенче олы сәбәп: планетабызда яшәүче теләсә-кайсы ил үзенә хак билгеле бер дәрәҗәдә әле генә ягъни алдарак әйтелгән система колына әверелгән. Әйе, бу система нигезендә (төп тышкы сәбәп) без, Коръән Кәрим әйтүе буенча, котылгысыз һәм коточкыч кыямәт көненә барабыз. Ә кем гаепле? Үзебез! Безнең җан тынычлыгын имин итәргә тиешле хакимият, матди байлык, "авторитетка" ия булган түрәләр (депутатлар) безне иң куркыныч упкынга - кыямәттәге җәзага илтәләр. Ничек дисезме? Чөнки алар тарафыннан Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен дип эшләү юк... Һәм өстәп шуны әйтәсе килә, кешелек тарихында бу төрдәге хакыйкатькә кагылган илләр һәм халыклар бихисап булган... Әйе, бу сорау бик катлаулы һәм аны әлегә тиз генә тормышка ашырырга мөмкин түгел...

Өченче сәбәп - җир йөзендә әлегә үзара килешә алмаган төрледән-төрле диннәрнең күплеге. Хак дин - ислам динебездә дә әлегә дүрт мәзһәбкә (хәнәфи, малики, шафигый һәм хәбәли) һәм 73 агымга яки төркемнәргә бүленгән булуы... Бу сәбәптән котылуның иң яхшы юлларының берсе - Коръән Кәрим һәм Сөннәт нигезендәге дәгъватны бик тә акыллы рәвештә халыкара дәрәҗәдә җәелдерү.

Ахыры 3нче биттә

Ахыры. Башы 2нче биттә

# Күңел тынычлыгы - тән сәламәтлегенең нигезе

Дүртенче һәм бишенче сәбәпләр - турыдан туры кешенең җан тынычлыгына тәэсир итүчеләре: яши торган өебездәге тәкъвалык рухы дәрәҗәсе һәм кешенең акылы-фигыле белән бәйләнгән гамәлләр. Әйе, бу һәркемгә кагылган сорауларның нечкәлекләренә тукталу мөмкинлеге булмау сәбәпле, әһәмиятлерәк берничә тирән кысқача гына булса да аңлатып китәбез. Бу сәбәпләргә кереш сүз буларак шуны әйтәсе килә - җан тынычлыгына тискәре йогынты ясаучы сәбәпләрне Аллаһы Раббыбыз рәхмәте белән азмы-күпме киметү һәм яшәешебезнең уңай энергиясен арттыру - һәрберебезгә фарыз гамәл. Ә бу үз чиратында һәркайсыбыз тарафыннан аз гына булса да җир шарыбызның аурасына уңай энергия өсти. Ягъни уй-фикерләребез (шулай ук матди матдә) һәм гамәлләребез белән "чирләтмик" җиребезнең аурасын дип әйтүем. Ә хәзер аз гына булса да тукталып китәм акылның җаныбызны тыңламыйча гөнаһлы уй-фикерләргә һәм гамәлләргә хирыс булуына. Әйе, безне туга хәзерге дөньяга тәрбияли башлыйлар. Гаиләдә, балалар бакчасында һәм мәктәптә безнең акылга, ягъни баш миенең клеткаларына "тутыралар" матди тәрәккыят белән бәйле булган дөньяви фәннәрне һәм бүгенге көн белән генә нигезләнгән тәгълиматны. Озын сүзнең кыскасы, безнең мәгариф системасы сәләтле түгел үзенчә төрле варианттагы уй-фикерләр нигезендә уйлауга һәм сөйләүгә юнәлгән укытуга (мәсәлән, ислам дине фәннәре нигезендә) ягъни кешенең асылын дөрес юл белән тәрбияләргә һәм укытуга. Бүгенге көндә безнең өчен күңелебездәге рухи сафлык мөһим. Гыйльме рух галимнәре: "Безнең чорда гуманистик юнәлеш бөтен кешелекнең исән калуы өчен иң мөһим шарт", - диләр. Ягъни кече яшьтән ирек бирергә җаннары кушуы буенча уй-фикер йөртергә һәм матди байлыклар белән бәйләнмәгән хакыйкый Илаһият фәннәре нигезендә укытырга һәм тәрбияләргә. Ягъни укытырга һәм тәрбияләргә һәрьяклап җәмгыятебезгә әхлакый кыйбла гына бирә торган тәкъвалык сыйфатларына ия булган шәхесләр.

Ә хәзер тукталабыз - ничек итеп ирешергә җаныбызның тынычлыгына (чагыштырмача гына булса да) безгә мәгълүм булган хакыйкый ислам динебез нигезендә. Иң башта өебездә (ишек аллары, җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчалары, мал-туарлар һ.б.) тәкъвалык рухы булу шарт. Ягъни өебезгә теләсә-кайсы вакытта фәрештәләргә керергә мөмкинлек булу өчен һәм аларга Корьән Кәрим укуда, намазлар вакытында, догалар кылганда катнаша алсыннар өчен кирәк өебездәге бу тәкъвалык рухы. Ягъни өебезнең мохите туры килергә тиеш шәригать кануннарына. Теләсә-нинди гөнаһ кылудан ерак йөрергә ягъни җиребезнең аурасына уңай энергия өстәү ягын гына әйдәргә ислам динебез нигезендә. Мәсәлән, сез авырый башладыгыз яки авырыйсыз? Иң беренче акылыгыз белән "ах-ух" килмичә (сабырлык нигезендә дип әйтүем) җаныгызның юнәлеш бирүе белән бергә ачыкларга бу авыруның сәбәпләрен! Әйе, аның сәбәпләре бихисап, әмма аның төп сәбәпләре санаулы гына:

1) бу авыруны Аллаһ Раббыбыз бирергә мөмкин безнең иманның ныклыгын ачыклау өчен;

2) мөселманның тугрылыгын, яки сабырлыгын, яки хәсбилеген, яки ихласлыгын сынау өчен;

3) кылган гөнаһлардан пакълану өчен;

4) Аллаһ Раббыбыз тарафыннан ислам дине юлында күрсәткән тугрылыгы һәм сабырлыгы нигезендә дәрәҗәсен тагын да югарырак күтәрү өчен;

5) сезнең авыруыгызның нигезендә булырга мөмкин нәселдән килә торганы;

6) шулай ук авыруның нигезендә булырга мөмкин дөрес яшәмәү рәвеше;

7) гыйльме рух һәм педагогика белән яхшы таныш булган тыйб (медицина) галимнәре өйрәтүе буенча авыруларның 80 проценты артыгы бәйләнгән турыдан -туры кешенең характерына һәм уй-фикерләү рәвешенә;

8) сихерчелек белән бәйле авырулар; сихерчелеккә керә бозым яки ырым, мәгънәсез сүзләр тезмәсе уку, күз тию белән бәйле сихер, көнкүрештәге теге яки бу әйберне кулланып кешенең уңай яшәү рәвешенә зыян китерү, йолдызнамәләр ягъни һәммә төрле күрәзәлек (фал), бернинди файдасы булмаган һәммә төрле бөтиләр һәм догалар, кеше белән бәйләнештә булган предметлар (тарак, чәч, күрем каны, мәетне юган су һ.б.) белән бәйле сихерләр, нәрсәләрдер укып ясалган төнәтмәләр һәм кайнатмалар, акылга сыймаган дәвалау ысуллары, Аллаһы Раббыбыз исеме белән бәйле булмаган Корбан чалулар һ.б.;

9) заманави йогышлы чирләр (ВИЧ, СПИД, сифилис, үләт һ.б.).

Безгә, ягъни мөселманга, авырудан дәвалану тышкы сәбәп кенә, ә шул ук вакытта без белергә тиеш дәваның шифасы Аллаһы Раббыбыз тарафыннан гына икәнен. Бу хәзерге тыйб, гыйльме рух һәм башка фәннәр белән расланган. Мәсәлән, гыйльме рух буенча Нидерланд галиме Ван дер Ховен үзенең өч еллык тәҗрибәләре нигезендә Корьән Кәримнең бик зур шифага ия булганын дәлилли. Ул "Аллаһ" сүзенең психик авыруларны дәвалаганда уйнаган ролен бигрәк тә басым ясап исбатлый: "беренче хәреф ягъни "һәмзә" белән "әлиф" сулышны контрольдә тотып, сулыш юлының эшчәнлеген яхшырта, "ләм" хәрефе сулышны җиңеләйтә, ә ахыргы хәреф "һә" үпкә белән йөрәкне тоташтыра һәм шул ук вакытта бу тоташу йөрәк тибешен нормага кертә. Ә бу процесс үз чиратында психик авыруларның нерв системасының эшчәнлеген уңай якка яхшырта", - ди. Шулай ук ислам дөньясына билгеле һәм атаклы галим Ибне әл-Кайим үзенең хезмәтләрендә яза: "Корьән - бар дөнья һәм ахирәт сырхауларына, җан һәм тәннең бар чирләренә дә камил шифа. Тик аннан шифа алырга күпләр сәләтле түгелләр. Әгәр дә авыру кеше Корьән белән уңышлы дәваланган, аны үзенең бар тугрылыгын, итагате, инанулары һәм иманы белән авыруга каршы юнәлткән, аның бар таләпләрен дә үтәгән икән, - авыру аңа каршы тора алмый", - дип. Дәвам итеп: "Корьәндә җан һәм тәннең бар чирләренең дә сәбәбе күрсәтелгән, аларны дәвалау ысуллары да, һәм шулай ук Аның Китабын аңлаучыларга сырхаулардан саклану юллары да", - дип аңлата ул үзенең хезмәтләрендә. Әле генә әйтелгәннәрдән чыгып, җаныбызның тынычлыгына ирешүнең иң үтемле юллары: Корьән Кәримне даими уку. Уку әдәбен тиешенчә үтәү. Галимнәрнең әйтүе буенча Корьәннең аерым сүрәләре һәм аятьләре зур энергиягә ия. Ә бу энергия ярдәмендә мөселман үзенең җан тынычлыгына тизрәк ирешә ала: "Әл-Фатиха" (Ачучы) сүрәсе һәм "Бәкара" сүрәсенең 285-286нчы аятьләре ("... боларда укылачак һәрбер хәрефе өчен теләгәнең һичшиксез бирелячәктер", - ди Пәйгәмбәребезгә (с.г.ү.с.) беренче тапкыр гына җир йөзенә ингән бер фәрештә); "Бәкара" (Сыер) сүрәсенең 255нче аяте, ягъни "Аятел Көрси"; шулай ук "Бәкара" сүрәсенең 163-164 аятьләре; "Әли Гыймран" сүрәсенең 18-19нчы аятьләре; "Әнгам" (Терлек) с. 54-56 а.; "Әграф" (Пәрдә) с. 117-122 а.; "Юныс" с. 81-82 а.; "Та һа" с. 69 а.; "Мөэминүн" с. 115-118 а.; "Саффат" с. 1-10 а.; "Әхкаф" с. 29-32 а.; "Рәхман" с. 33-36 а.; "Хәтер" сүрәсенең 21-24 а.; "Тәгабүн" с. 14-16 а.; "Җен" с. 1-9 а.; "Ихлас" сүрәсе һ.б. Хәзерге вакытта киң таралган төрле дәрәҗәдәге стресс һәм депрессияләрне, төшенкелекне, куркуны, үзеңә ышанычсызлыкны, киеренкелекне, даими тискәре хисчәнлекне һ.б. бик яхшы сихәтли. Әгәр Корьән Кәримдәге берничә сүрәне көн дә һәм дә ки борчылган вакытта, түбәндә бирелгән тәртиптә укысаң: "Әл-Фатиха", "Бәкара" сүрәсеннән 255 аятьне, "Әл-Кәфирун", "Ән-Насыр", "Әл-Ихлас", "Әл-Фәләкъ" һәм "Ән-Нәс";

-Пәйгәмбәрләрнең Солтаны (с.г.ү.с.) авырып китсә, ике учына куль әгүзү бираббиль фәләку үә куль әгүзү бирабби нәс сүрәләрен укып, соңыннан куллары белән бөтен гәүдәсен сыпыра иде дигән аның хатыны хәзрәти Гайшә;

-иң киң таралган юлларның берсе - өшкерү. Шәригать кануннары буенча өшкерүнең шартлары берсүзсез үтәлергә тиеш:

Түгәрәкләп шуны әйтәсе килә, әгәр без ислам диненә ышанучылардан булсак һәм дә ки аның таләпләрен ихлас күңелдән үтәсәк, шифа энергиясенең куәте бермә-бер көчле булачак

**КАМИЛ ХИСМӘТОВ,**
**Мамадыш мәдрәсәсенең 3 нче курс шәкерте, гер спорты буенча ике тапкыр Гиннес рекордчысы**

**Камил уйлар**

## Бәхет нәрсә ул

**Хәсән әл-Басри әйткән: "Бәхет – безнеке. Әгәр моны патшалар һәм аларның уллары белсәләр икән, алар бу бәхетне яулар өчен безгә каршы кылыч тотып көрәшерләр иде". Аннан тагын: "Бәхет нәрсә соң ул?" – дип сораганнар. Ул: "Бәхет – Аллаһка буйсынып яшәүдәндер!" – дип җавап биргән. Бер Аллаһы Раббым-Гыйззәгә генә иманулның бәхете шунда: син Бөек Аллаһ Раббыбызны танып, Аңа ышанып, Аның бары тик бер генә булуын, һәрнәрсәне юктан бар кылуын, ризыкландыручы, хөкемдар, без күз алдына китерә алмаган гыйлем иясе һәм һәрнәрсәне булдыра алучы икәнне таныйсың. Бер Бөек Хак Тәгаләгә генә ышанучының бәхете шул – синең җаның бары тик Аңа гына бәйләнгән. Җәннәт ул – бер. Хакимнәрнең Хәкиме Бөек һәм Мактауга лаек Аллаһыга гына буйсыну, Аннан гына курку, Аны гына ярату, өметләнү, канәгать булу, яшәвең дә һәм үлүең дә Аның өчен генә. Бары тик Аллаһы Раббыбыз гына безне хөкем итә. Йә җәза бирә, йә җәннәт белән бүләкли. Бер хакыйкый җәннәт..**

◆ ХИКӘЯ

# Әнкәй куллары

Беркөнне әнием үзе белән кибетләрдә йөрүемне үтенде. Аның ниндидер кием аласы бар иде. Кибетләрдә озак йөрергә сабырлыгым җитмәгәнгә, җае чыккан саен мондый сәяхәтләрдән кача идем. Ләкин әнкәйнең үтенечен кире кагып булмый бит! Барырга ризалашырга туры килде. Сәүдә үзәгенә килеп җиткәч, без бер кибеттән икенчесенә йөри башладык. Һәр кергән җирдә дә әнкәй сатучылар тәкъдим иткән киемнәрнең әле берсен, әле икенчесен киеп карый, ләкин җанына ошаганын таба алмый иде. Шулай бик озак сайланып, йөрдек тә йөрдек. Ачуым чыга башласа да, әнкәмә сиздермәдем, аны юатырга тырыштым. Йөри торгач, ниһаять, әнкәмнең игътибарын итәк, блузка һәм жакеттан торучы матур гына зәңгәр костюм җәлеп итте. Әниемне кием киеп карый торган бүлмәгә алып кертеп җибәрдем. Берничә минуттан соң әнкәй оялып кына миңа эндәште. Мин аның янына кердем. Әнкәм блузканы кигән дә арттагы берничә сәдәфен эләктерә алмый газаплана иде. Артриттан кәкрәеп каткан бармаклар әнкәемне тыңламыйлар, кечкенә сәдәфләрне эләктерү аңа уңайсыз. Күзем әнкәмнең кулларына төшү белән сабырсызлыгым да, ачу килүем дә әллә кая эреп юкка чыкты. Бөтен барлыгымны кызгану һәм ярату хисе биләп алды. «Менә тамам" дип, күзләремне



каплаган яшь тамчыларын яшерү өчен, мин читкә борылдым... Үземне кулга алып, сәдәфләрне тиз генә каптырдым. Ләкин бармакларым хыянәтчел рәвештә калтырыйлар иде. Әнкәм моны сизеп: «Балам, сиңа нәрсә булды?" – дип сорады. «Юк, юк, берни дә булмады, бар да тәртиптә", - дидем мин, әнкәмнән күзләремне яшереп. Костюмны сатып алгач, без өйгә кайтып киттек. Кибетләргә сәяхәтебез шулай тәмамланды, ләкин бу көн хәтеремдә мәңгегә уелып калды. Өйгә кайткач та сәдәфләрне эләктерергә тырышучы әнкәм куллары күз алдымнан китмәде. Әлеге куллар – дөньядагы иң кадерле, иң җылы куллар. Алар мине ашаткан, юындырган, киендергән. Әнкәм куллары – иң кайгыртучан куллар. Алар миңа әниемнең җан җылысын, назын, мәхәббәтен биргән. Кулларын күтәреп, әнкәм минем өчен дога кылган. Миңа исәнлек-саулык, иман-тәүфыйк сораган. Үзеңне яратучы, кайгыртучы әнкәйнең кул җылысын һичбер вакыт онытып булмый.

Кич белән түзмәдем, әнием янына кереп, аның кулларын учларыма алдым. Һәм, әнкәйне гаҗәпкә калдырып, аларны үбә башладым. «Әнием! – дидем, тавышым дулкынланудан калтырап чыкты. – Әнием, синең куллар – дөньядагы иң җылы, назлы куллар. Кайчан да булса минем дә кулларым һәм йөрәгем синеке кебек булсын иде, - дип, мин дога кылам. Рәхмәт сиңа, әнкәй, рәхмәт, барсы өчен дә..." Шунда без, кочаклашып, икебез дә елап җибәрдек...

**Р. СӘРВАРОВА**

**Камил аганың файдалы киңәшләре**

## Озын гомерле булуның кайбер гади серләре

1. Хәрам һәм мәкруһ гамәлләр башкармагыз! (исерткеч эчемлекләр эчү, тәмәке тарту, дуңгыз ите ашау, гайбәт сөйләү, аяк өстендә ашау h.б)
2. Бәдәннең (гәүдәнең) массасыниләр сөйли:
Корсактагы артык бер кг авырлык өч ел гомерне ала;
Гәүдәнең артык бер кг авырлыгы безнең яшәүне бер елга кыскарта;
Артык авырлык санап бетермәслек авырулар чыгара.
3. 5 вакыт намаз уку безне Аллаһы Раббыбызга якынайтудан тыш 20-25 ел гомеребезне дә озынайта.
4. Хәрәкәттә – бәрәкәт! Хәрәкәтләнмәгән кеше шатлана белүен дә оныта диләр.
5. Гыйльме рух галимнәр әйтүе буенча акыл (иҗади) эшчәнлеге безнең организмга тиз генә картаерга ирек бирми.
6. Иртә өйләнгән яки кияүгә чыккан гаиләле кешенең гомере шулай ук 20-25 елга артык.
7. Антиоксидантларга (кишер, кәбестә, шәфталу (персик), өрек, абрикос, җир җиләге, балык, гранат, яшел чәй h.б) бай азыкларны еш ашарга тырышыгыз!
8. Ир-атлар колагына:
Хатын-кызларга кычкыру стрессларны җиңәргә ярдәм итә һәм аның сәламәтлегенә дә уңай тәэсир ясый, ә менә ир-атларга кычкырырга ярамый, чөнки аларга кычкыру йөрәк кан тамыры авыруларына китерергә мөмкин дип өйрәтәләр тыйб (медицина) галимнәре.
9. Бер атнага 5 әстерхан чикләвеге (грецкий орех) ашарга тырышыгыз, чөнки ул гомерне якынча 7 елга озайта.
10. Көненә бер алма ашау кешегә уртача 3 елга артыграк яшәргә мөмкинлек бирә.

**(Дәвамы киләсе санда)**

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.
Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.
Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета "Татмедиа" ААҖнең Мамадыш муниципаль районы"Нократ" мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 400 данә.**